РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
НИЖНЕКАМСКИЙ
ГОРОДСКОЙ СОВЕТ
пр. Строителей, д. 12, г. Нижнекамск, 423570

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ТҮБӘН КАМА ШӘҺӘР
СОВЕТЫ
Төзүчеләр пр., 12 нче йорт, Түбән Кама шәһәре, 423570

Тел./факс: (8555) 42-42-66. E-mail: Gorsovet.Nk@tatar.ru

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

2023 елның 7 декабре № 52

2020 елның 15 октябрендәге 12 номерлы «Җир салымы турында» Түбән Кама шәһәр Советы карарына үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Салым кодексының 31 бүлегенә, «Түбән Кама шәһәре» муниципаль берәмлеге Уставына туры китереп, Түбән Кама шәһәр Советы

КАРАР БИРӘ:

1. Түбән Кама шәһәр Советының 2020 елның 15 октябрендәге 12 номерлы «Җир салымы турында» карарына түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1.1 4 нче пунктны түбәндәге эчтәлектәге 4.1.8 нче пункт белән тулыландырырга:

«4.1.8. Россия Федерациясе Президентының «Россия Федерациясендә өлешчә мобилизация игълан итү турында» 2022 елның 21 сентябрендәге 647 номерлы Указы нигезендә Россия Федерациясе Кораллы көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган Россия Федерациясе гражданнарына, шулай ук Түбән Кама шәһәрендә яшәү урыны буенча теркәлгән, хәрби хезмәткәр статусына ия булган һәм махсус хәрби операциядә катнашучылар,, салым объекты милекчеләренә һәм салым түләүчеләргә - шул ук объектта милек хокукына ия булган гаилә әгъзаларына.

Гаилә әгъзаларына аның белән бергә теркәлгән ир (хатын), балигъ булмаган балалар (шул исәптән тәрбияләнүчеләр) һәм ата-аналар керә.

Салым ташламасына хокуклы салым түләүче сайланган салым салу объекты турында хәбәр итмәсә, салым ташламасы максималь исәпләнгән салым суммасы булган бер салым салу объектына карата бирелә.».

1.2 5 нче пунктны түбәндәге эчтәлектәге икенче абзац белән тулыландырырга:

«Салым түләүчегә тиешле салым суммасын билгеләгәндә, әлеге карарның 4.1.8 пунктында каралган салым ташламасы салым түләүчене сайлау буенча салым салуның бер объектына индивидуаль торак төзелеше, шәхси ярдәмче хуҗалык, блокланган торак төзелеше, бакчачылык алып бару өчен рөхсәт ителгән файдалану төре белән бирелә.».

2. Әлеге карар рәсми рәвештә басылып чыккан көннән үз көченә керә һәм 2022 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

Түбән Кама шәһәре Мэры Р.Х. Муллин